**ГЛАВА**
**Кучуковского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Көчек авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.11.2024 Түбән Көчек авылы № 3

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Түбән Көчек авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлеге Уставының 14 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлеге Башлыгы к а р а р ч ы г а р д ы:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Түбән Көчек торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2024 елның 22 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга: “2025 елда үзара салым акчаларын кертү өчен «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Түбән Көчек авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, I төркем инвалидлардан, студентлардан тыш, көндезге формада белем алучы гражданнардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, ирекле киткән) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатыннарын, балигъ булмаган

балаларын) түләүдән азат итү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юллау белән килешәсезме:

1. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Казан урамындагы һәм К. Маркс урамындагы Түбән Көчек авылының 37 нче һәм 39 нчы йортлары арасындагы юлнына вак таш сатып алу һәм салу), һәм автомобиль юлларын карап тоту буенча башка чыгымнар);

2. Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (суүткәргеч челтәрен ремонтлау өчен сантехник һәм чыгым материаллары сатып алу, су җыю манараларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, су җыю манарасын һәм су белән тәэмин итүне карап тотуның башка чыгымнары);

3. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү автомашинасын тоту: ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу һәм башка хезмәтләр күрсәтү);

4. Тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (электр товарлары сатып алу һәм урам яктырткычлары урнаштыру, урам яктыртуны карап тоту буенча башка чыгымнар, электрикка хезмәт шартнамәсе буенча түләү);

5. Түбән Көчек торак пункты урамнарын кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу һәм тракторчыга килешү буенча хезмәт хакы түләү;

- авария хәлендәге һәм коры яшеллекләрне, куакларны кисү;
- үләннәрне һәм чүп үләннәрен чаптыру;
- МТЗ-82 тракторын тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү;
- тракторга тагылма җайланма (арба)сатып алу;
- территорияне төзекләндерү буенча башка чыгымнар
- МТЗ -82 тракторын карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Түбән Көчек авылы, Ленин урамы, 12 йорт, авыл мәдәният йорты бинасы каршындагы мәйданчык.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлеге мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе Урынбасары,
Авыл җирлеге башлыгы урынбасары А.Р.Тухватуллина

Совет Кучуковского сельского поселения
Көчек авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002526
АГРЫЗСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ